ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

## Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясына үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 20 октябрендә
кабул ителде

### 1 статья

Татарстан Республикасы Экология кодексының 2 статьясындагы 1 өлешенең егерме тугызынчы абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 57 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«лицензия – юридик зат яисә индивидуаль эшкуар тарафыннан эшчәнлекнең конкрет төрен (эшчәнлекнең лицензияләнә торган төренә кергән эшләр башкару, хезмәт күрсәтү) гамәлгә ашыру хокукына лицензияләр реестрында язма белән раслана торган махсус рөхсәт;».

### 2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 02 ноябрь
№ 74-ТРЗ